КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 март г.Казань № 187

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 25 май, 298 нче; 2018 ел, 21 май, 384 нче; 2019 ел, 25 гыйнвар, 38 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турындагы нигезләмәдә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе (алга таба – премия) әдәбият (шигърият, проза, әдәби тәрҗемә, публицистика, әдәби тәнкыйть) өлкәсендә Г.Р.Державин иҗатын популярлаштыра торган, рус һәм (яки) татар телләрендә иҗат ителгән, киң җәмәгатьчелектә танылган аеруча күренекле әсәрләре өчен язучыларга һәм юриспруденция өлкәсендә фәнни тикшеренүләре (монографияләре) өчен юристларга бирелә. Әсәрләр һәм тикшеренүләр (алга таба – эшләр) соңгы биш ел эчендә, әмма премия алырга дәгъва итүгә кадәр бер елдан да соңга калмыйча басылып чыккан булырга тиеш.»;

4 нче пунктның беренче абзацында «сигез» сүзен «биш» сүзенә алыштырырга;

18 нче пунктның беренче абзацында «ачык» сүзен «яшерен» сүзенә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе комитеты составында:

Комитет составыннан М.П.Афанасьевны, Р.И.Вәлиевны, И.Р.Гафуровны, Г.Р.Нигъмәтуллинаны чыгарырга;

Комитет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Казан рус милли-мәдәни берләшмәсе» җирле иҗтимагый оешмасы рәисе Ирина Алексеевна Александровскаяны (килешү буенча);

«Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясы» төбәк иҗтимагый оешмасының башкарма комитеты җитәкчесе Николай Михайлович Владимировны (килешү буенча);

Е.А.Боратынский музее – «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы мөдире Ирина Васильевна Завьялованы (килешү буенча);

Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Илдус Фатыйх улы Зариповны (килешү буенча);

югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең беренче проректоры Рияз Гатаулла улы Минзариповны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы Ләйсән Гаптелхан кызы Низамованы;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәетгәрәй улы Сәлимгәрәевны;

Айрат Ринат улы Зариповның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча)»;

Римма Атлас кызы Ратникованың вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының законнарның татар һәм рус телләрендәге текстларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе рәисе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин